**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 августындагы 3250 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә, проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне дә кертеп) дәүләт экспертизасы, муниципаль биремгә кертелмәгән дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы уздыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 8 декабрендәге 4290 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә, проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне дә кертеп) дәүләт экспертизасы, муниципаль биремгә кертелмәгән дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы уздыруга

башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 1 августындагы
3250 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә, проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы, муниципаль биремгә кертелмәгән дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы уздыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә (алга таба – учреждение), проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы, муниципаль биремгә кертелмәгән дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы уздыруга башка субсидия (алга таба – башка субсидия, субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен билгели.

Субсидия Учреждение чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен түбәндәге максатларга бирелә:

- проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне дә кертеп);
- дәүләт экология экспертизасын үткәрү;
- дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын үткәрү.

1.2. Башка субсидия Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенең (алга таба – Идарә) структур бүлекчәсе булган Учреждениегә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган буларак Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан бирелә, аңа, бюджет акчаларын алучылар буларак, тиешле финанс елына һәм план чорына максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары

билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Учреждение Идарәгә электрон документ рәвешендә uag.kazan@tatar.ru электрон почта адресысына яки язма рәвештә 420012, Казан шәһәре, Груздев урамы, 5 йорт адресы буенча, максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге буенча тапшырылган документлар исемлеген беркетеп, әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча гариза тапшыра, документлар исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- субсидия суммасын исәпләү-нигезләүне, шул исәптән тиешле эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә), чаралар үткәрүгә, милек (күчемсез милектән кала) сатып алуга башлангыч сметаны кертеп, бюджет акчаларын әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән максатларга бирү кирәклеген нигезләүне, шулай ук тәэминатчыларның (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистик мәгълүматларны һәм (яки) башка мәгълүматны үз эченә алган аңлатма язуын;

- Учреждениенең әлеге Тәртипнең 2.8 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларны.

2.2. Идарә:

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) өч эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар җыелмасының тулы булуын, алардагы мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә;

в) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турында яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Кирәкле барлык документларны тапшырмаган яисә аларны тиешенчә тутырмаган очракта, Идарә, карап тикшерү вакыты тәмамланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен әлеге документларны кире кайтара.

Хәбәрнамә Учреждениегә Идарәгә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә Идарәгә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Учреждение тарафыннан җитешсезлекләрне бетерү вакыты – әлеге хәбәрнамә теркәлгәннән соң биш эш көненнән артык түгел.

Ачыкланган җитешсезлекләр төзәтелгәннән соң кабат кергән гариза Идарә тарафыннан әлеге пунктта билгеләнгән тәртиптә һәм вакыт эчендә карап тикшерелә.

2.3. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән максатларга туры килмәве;

- Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

- Идарәнең бюджет исемлегендә каралган бюджет йөкләмәләре лимитларын агымдагы финанс елында максатчан субсидияләр бирүгә тулысынча бүлү.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, учреждениегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүдән баш тарту сәбәбен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәрнамә җибәрелә.

Баш тарту турында хәбәрнамә Учреждениегә Идарәгә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә Идарәгә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Баш тарту өчен нигез булып торган җитешсезлекләр төзәтелгән очракта, учреждение документларны кабат җибәрергә хокуклы.

Учреждение тарафыннан документларның тулы җыелмасы тапшырылган һәм тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында билгеләнгән максатларга туры килгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында каралган максатчан субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Идарә әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә Учреждениегә субсидия бирү мөмкинлеге турындагы бәяләмә рәвешендә максатчан субсидия бирү турында карар кабул итә.

2.4. Башка субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З1 + З2 + З3 + \ldots + Зn,$$ монда:

С – муниципаль биремгә кертелмәгән проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне дә кертеп), дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт

тарихи-мәдәни экспертизасы нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыруга субсидия күләме;

З1, З2, З3, …, Зn – субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карар, Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль программаны раслау турындагы карары белән билгеләнгән очраклардан кала, проект документларына һәм инженерлык эзләнүләренә дәүләт экспертизасын (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне кертеп), дәүләт экология экспертизасын һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасын үткәрүгә бәйле, Учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә тапшырылган документлар нигезендә билгеләнгән чыгымнар.

Субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын алучы буларак максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Идарәгә тиешле финанс елына һәм план чорына билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

2.5. Максатчан субсидия бирү максатыннан Идарә һәм Учреждение арасында Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан раслана торган үрнәк форма нигезендә килешү (алга таба – килешү) төзелә, анда шул исәптән түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) әгәр субсидияләр тиешле программаларны, проектларны гамәлгә ашыру максатыннан бирелсә, милли проект (программа) исемен күрсәтеп, субсидия бирү максатлары, шул исәптән тиешле милли проект (программа) составына керүче муниципаль проект яисә муниципаль программа максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче муниципаль проект исемнәрен күрсәтеп, субсидия бирү максатлары;

б) төгәл, үлчәнелә торган һәм әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән (субсидия мондый программаларны, проектларны гамәлгә ашыру максатыннан бирелгән очракта) муниципаль проектлар, муниципаль программалар (муниципаль программаларда мондый программаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булганда) нәтиҗәләренә туры килергә тиеш булган субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре, матди һәм матди булмаган объектлар күрсәткечләрен һәм (яисә) тиешле программаларның, проектларның нәтиҗәләренә ирешкәндә файдаланырга планлаштырылган хезмәтләрне кертеп (мондый детальләштерү мөмкинлеге булганда), субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр;

в) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы;

г) субсидия күләме;

д) субсидияне күчерү вакыты (графигы);

е) хисап бирү вакыты;

е) Учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм вакытлары;

з) килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак Идарәгә субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләренең алдан җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта;

и) Идарә карары буенча килешүне вакытыннан алда, берьяклы тәртиптә, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә туктату өчен нигезләр:

- Учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) яисә ябу;

- Учреждениенең хокукый актта һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуы;

и) Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю;

л) башка нигезләмәләр (кирәк булганда).

Бюджет йөкләмәләре лимитларын максатчан субсидияләр бирүгә кадәр җиткергәннән соң, Идарә килешү проектын төзи.

2.6. Максатчан субсидия субсидияләр алу һәм алардан файдалану операцияләрен исәпкә алу өчен Федераль казначылык органында Учреждение тарафыннан ачылган шәхси счетка, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып, 10 эш көне эчендә күчерелә.

2.7. Әлеге Тәртипнең 1.1 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән башка субсидия бирү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә карата – инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламентлар таләпләренә туры килүе (уңай бәяләмә) яисә туры килмәве (тискәре бәяләмә) турында бәяләмә;

2) проект документациясенә карата – бәяләмә:

проект документациясенең инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, проектлау биременә һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүе (уңай бәяләмә) яки туры килмәве (тискәре бәяләмәсе) турында;

законнарда билгеләнгән очракларда капиталь төзелеш объектлары төзелешенең смета бәясен билгеләүнең дөреслеге (уңай бәяләмә) яисә дөрес түгеллеге (тискәре бәяләмә) турында.

Учреждение тарафыннан вәкаләтле органга – «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм

бәяләр билгеләү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 30 сентябрендәге 151/о номерлы боерыгы белән расланган проектлау документларына һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 4 номерлы кушымтасында күрсәтелгән исемлек нигезендә җыелган документлар белән гариза бирүе субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч булып тора.

Экспертиза объектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә ниятләнә торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне нигезләүче документларның һәм (яисә) документациянең әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда һәм техник регламентларда билгеләнгән экологик таләпләргә туры килүе турында нигезләнгән нәтиҗәләрне үз эченә ала торган, вәкаләтле орган тарафыннан расланган дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе әлеге Тәртипнең 1.1 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән башка субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып тора.

Учреждение тарафыннан вәкаләтле органга билгеләнгән форма буенча дәүләт экология экспертизасын оештыру һәм уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза әзерләү һәм тапшыру субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч булып тора.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 25 апрелендәге 530 номерлы карары белән расланган Дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы турындагы нигезләмә таләпләре нигезендә акт рәвешендә рәсмиләштерелгән бәяләмә әлеге Тәртипнең 1.1 пунктының бишенче абзацында күрсәтелгән башка субсидияне бирү нәтиҗәсе булып тора.

Учреждение һәм эксперт арасында килешү төзү субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч булып тора.

2.8. Учреждениене үзгәртеп оештыру яисә ябу буенча чаралар үткәрүгә, авария (гадәттән тыш) хәлен булдырмауга, авария (гадәттән тыш) хәле килеп чыккан очракта, аның нәтиҗәләрен бетерүгә һәм торгызу эшләрен башкаруга, законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычны каплауга субсидия бирү очракларыннан кала, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенә караган югары башкарма органының норматив хокукый актлары, Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очраклардан кала, Учреждение субсидия бирү турында килешү төзү яисә карар кабул итү планлаштырыла торган айга кадәрге айның

беренче көненә Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә Учреждениенең түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча түләнмәгән бурычлары булмавы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актларга нигезләнеп бирелгәннәрен кире кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы булмавы турында таләпләргә туры килергә тиеш.

## III. Хисап бирүгә таләпләр

3.1. Учреждение бирелгән субсидиядән файдалану турында, шул исәптән Учреждение тарафыннан тотылган чыгымнар турында һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында килешүдә билгеләнгән формалар буенча әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән вакытта Идарәгә хисап (алга таба – хисап) тапшырырга тиеш.

3.2. Учреждение максатчан субсидия бирү елыннан соң килүче финанс елның 15 гыйнварына кадәр Идарәгә хисап бирә.

3.3. Бирелгән максатчан субсидиядән файдалану турында хисап бирү формасы, тәртибе һәм сроклары Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан билгеләнә.

## IV. Субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

4.1. Максатчан субсидияләрнең агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланмый калган өлеше Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

4.2. Хисап елыннан соң килә торган финанс елының 15 гыйнварына кадәр Идарә Казан шәһәре Башкарма комитетынең Финанс идарәсенә, килешүдә билгеләнгән вакытларда кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле, максатчан субсидия акчаларының хисап елы булган финанс елында файдаланылмаган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле калган өлеше турында мәгълүмат җибәрә.

4.3. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган, Учреждение тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында файдалану турындагы карар Идарә тарафыннан кабул ителә.

Максатчан субсидияләр финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып

торган, Учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итү өчен Учреждение Идарәгә Учреждениенең Учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турында мәгълүматны, шулай ук Учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документларның күчермәләрен), акча килеп ирешкәннән соң, өч эш көне эчендә тапшыра.

Идарә, максатчан субсидия бирелгән вакытта билгеләнгән максатларга ирешү өчен, агымдагы финанс елында әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат кергән вакыттан алып 10 эш көне эчендә финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган түләүләрне кире кайтарудан барлыкка килгән керемнәрдән файдалану турында карар кабул итә.

4.4. Россия Федерациясе законнары нигезендә субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерү, шул исәптән субсидияләр биргәндә билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә Идарә, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.5. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча Учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, шулай ук Учреждение әлеге Тәртипнең III бүлегендә билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаган очракта, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.6. Максатчан субсидияне яки аның бер өлешен кайтару турында таләп Учреждение әлеге таләпне алган көннән алып 30 календарь көн эчендә Учреждение тарафыннан үтәлергә тиеш.

Субсидияне кире кайтару турындагы таләп билгеләнгән вакытта үтәлмәгән очракта, Идарә аны Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә.

4.7. Учреждение җитәкчесе максатчан килешүдә каралган шартлар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә субсидияләрдән файдаланган өчен җавап тота.

---

Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә, проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне дә кертеп) дәүләт экспертизасы, муниципаль биремгә кертелмәгән дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы уздыруга башка субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе карамагындагы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә муниципаль биремгә кертелмәгән проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре (билгеләнгән очракларда смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерүне дә кертеп), дәүләт экология экспертизасы һәм дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы уздыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка субсидия алуга
гариза

Субсидия бирүнең максаты: ____________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 3 | Төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН) | |
| 4 | Юридик адресы | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган белешмәләр тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында миңа әлеге гаризада хәбәр ителде ___________ (имза) | |

| | |
|---|---|
| 11 | Учреждениенең Тәртипнең 2.8 пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслыйм |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм Тәртип нигезендә исемлек буенча кирәкле документларны тапшырам |

Директор _______________________________________________

(имзасы, вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү көне: 20 _____ елның «____» _____________